**МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ» АТНИНСКОГО РАЙОННОГО ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘТНӘ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ "МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ" МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА ОЕШМАСЫ**

422750, с. Большая Атня, ул. Октябрьская, 9 Тел.: (843)-69-2–10–60. тел./факс: (843)-69- 2–10–46 E-mail: roo_atnja@mail.ru

№ 141–о/д от 22.10.2020г.

# Приказ

## О проведении конкурса чтецов «Туган телем - иркэ гөлем»

В целях сохранения и развития национальной культуры и языка ПРИКАЗЫВАЮ:

1. Провести с 09 по 18 ноября 2020г. среди воспитанников дошкольных и образовательных учреждений конкурс чтецов «Туган телем - иркэ гөлем».

2. Утвердить:

2.1. Положение районного конкурса (Приложение 1).

2.2. Состав жюри конкурса (Приложение 2).

3. Ответственным за проведение назначить методиста МКУ «Отдел образования» Нигматову Лейсан Ильфатовну.

**Начальник** **Л.Т.Гарипов**

Приложение 1
к приказу МКУ "Отдел образования"
Атнинского районного исполнительного комитета
№ 141-о/д от 22.10.2020г.

**Танылган татар шагыйрьләре Лена Шакирҗанованың һәм Фирая Зыятдинованың туууына 75 ел булуга багышланган "Туган телем-иркә гөлем" шигырь укучылар район бәйгесе нигезләмәсе**

**1. Гомуми мәгълүмат**

Конференцияне оештыру һәм аның белән гомуми җитәкчелек Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының "Мәгариф бүлеге" муниципаль казна оешмасы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Оештыручы жюри составын билгели, ул укучыларның тәкъдим ителгән эшләрен бәяли, җиңүчеләрне билгели.

**2. Бәйгенең максаты һәм бурылары:**

- укучыларны татар шигъриятенә, милли мәдәнияткә тарту;
- татар теленә, туган якка, Ватанга мәхәббәт хисе тәрбияләү;
- балаларда эстетик зәвык тәрбияләү;
- балаларның иҗади активлыгын үстерү.

**3. Катнашучылар.**

Конкурста мәктәпкәчә белем бирү оешмалары (5-7 яшьлек балалар) һәм гомуми белем оешмаларының 1-11 сыйныф укучылары катнаша.

**4. Үткәрү шартлары һәм тәртибе.**

Конкурс 2 этапта үткәрелә:

- 1 этап: 2020 нче елның 9 нчы ноябрьдән -14 нче ноябрь аралыгында мәктәпкәчә һәм гомуми белем оешмалары үзләрендә үткәреп 2 нче этапта катнашу өчен 3 кандидатны билгели;
- 2 этап: (муниципаль этап) 16 нчы ноябрьдән -18 нче ноябрь аралыгында мәктәпкәчә һәм гомуми белем оешмаларына заявка (кушымта 1) һәм видеоны nigmatova_89@mail.ru электрон почтасына җибәрергә.

Катнашучы Лена Шакирҗанованың яки Фирая Зыятдинованың бер генә шигырен сөйли. Шигырьләрнең темасы чикләнми.

**5. Катнашучыларның чыгышын бәяләү өчен критерийлар**

Катнашучылар 4 төркемдә бәяләнә:

- мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында йөрүче 5-7 яшьлек балалар;
- 1 - 4 сыйныф укучылары;
- 5 – 8 сыйныф укучылары;
- 9 – 11 сыйныф укучылары.

Конкурсантларның чыгышы төп критерийлар буенча ун баллы шкала буенча бәяләнә:

- башкарылучы шигырьнең конкурсантның яшь һәм индивидуаль үзенчәлекләренә туры килүе;
- башкару осталыгы: артистлык, тавыш яңгырашы, авторның сәнгатьле уку чараларын үтәве (логик басым, интонация, темп);
- сәхнә культурасы (кием, үз-үзен тотышы).

## 6. Бүләкләү

Призлы урыннар алган катнашучылар Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге” муниципаль казна оешмасы грамоталары белән бүләкләнә.

Белешмәләр өчен телефон:
8(84369)2-10-61, Нигматова Ләйсән Илфат кызы
Хөснетдинова Алсу Мисалим кызы
Гыйззатова Айсылу Рафиз кызы

Приложение 2
к приказу МКУ “Отдел образования”
Атнинского районного исполнительного комитета
№ 141-о/д от 22.10.2020г.

**Конкурсның жюри составы**

**Жюри рәисе:**

- Нигматова Ләйсән Илфат кызы – Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге”нең Милли мәгариф өчен җаваплы методисты.

**Жюри әгъзалары:**

- Хөснетдинова А.М. - Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге”нең укыту-методик бүлеге җитәкчесе;
- Гыйззатова А.Р.- Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге”нең тәрбия эшләре буенча җитәкче урынбасары;
- Һадиева Г.Ш. - Татарстан Республикасы Әтнә районы башкарма комитетының “Мәгариф бүлеге”нең мәктәпкәчә белем бирү буенча методисты.

Приложение

**“Туган телем-иркә гөлем”** шигырь конкурсында катнашу өчен заявка

| № | Ф.И.этисенең исеме | Район, мәктәп, сыйныф | Укытучының Ф.И.Әтисенең исеме. | Сөйләнәчәк шигырьнең исеме, авторы |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |